ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
МУНИЦИПАЛЬНОГО ОБРАЗОВАНИЯ
ГОРОД НАБЕРЕЖНЫЕ ЧЕЛНЫ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЯР ЧАЛЛЫ ШӘҺӘРЕ
МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

07 май 2025 ел № 3326

Башкарма комитетның 2023 елның 20 апрелендәге 3188 номерлы Карары белән расланган «Гомуми белем бирү программаларын гамәлгә ашыручы муниципаль белем бирү оешмаларына кабул итү турында гаризалар алу» муниципаль хезмәте күрсәтүнең административ регламентына үзгәрешләр кертү турында

«Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында» 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы Федераль закон, Россия Федерациясе Мәгариф Министрлыгының «Россия Федерациясе Мәгариф министрлыгының 2020 елның 2 сентябрендәге 458 номерлы боерыгы белән расланган Башлангыч гомуми, төп гомуми һәм урта гомуми белем бирү программалары буенча укырга кабул итү тәртибенә үзгәрешләр кертү турында» 2025 елның 4 мартындагы 171 номерлы боерыгы, шәһәр Уставының 41 статьясы, Шәһәр Советының 2007 елның 21 февралендәге 19/8 номерлы Карары белән расланган Муниципаль хокукый актлар системасы турында нигезләмәнең 5.24 пункты нигезендә

К А Р А Р  Б И Р Ә М:

1. Башкарма комитетның 2023 елның 20 апрелендәге 3188 номерлы Карары белән расланган «Гомуми белем бирү программаларын гамәлгә ашыручы муниципаль белем бирү оешмаларына кабул итү турында гаризалар алу» муниципаль хезмәте күрсәтүнең административ регламентына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 1.5 пунктка түбәндәге эчтәлектәге 1.5.8 пунктча өстәргә:

«1.5.8. Балалары чит ил гражданнары яки гражданлыгы булмаган затлар булган ата-аналар (законлы вәкилләр).»;

2) 2.6.1. пунктчаны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2.6.1. Хезмәттән файдалану өчен гариза бирүче түбәндәге документларны тапшыра:

63-ФЗ номерлы Федераль закон таләпләре нигезендә имзаланган кәгазьдәге документ формасында (административ регламентка 6 нчы кушымта, үрнәк форма (гариза формасы Оешма тарафыннан билгеләнә) яки ЕПГУ, РПГУ аша мөрәҗәгать иткәндә электрон формадагы гариза (интерактив формага тиешле мәгълүмат кертү юлы белән тутырыла);

баланың ата-анасының (законлы вәкиленең) яки укырга керүченең шәхесен раслаучы документның күчермәсе. ЕПГУ, РПГУ аша мөрәҗәгать иткәндә шәхесне раслаучы документтан алынган мәгълүматлар ЕСИАда хисап язмасын раслаганда тикшерелә;

бала туу турындагы таныклыкның күчермәсе яки гариза бирүченең туганлыгын раслаучы документ;

бер ата-анадан туган яки бер ата-анадан тумаган абыйсы һәм (яки) апасының туу турында таныклыгы күчермәсе (баланың бер ата-анадан туган яки бер ата-анадан тумаган абыйсы һәм (яки) апасы укый торган Оешмага башлангыч гомуми белем бирү программалары буенча белем алуга өстенлекле кабул итү хокукыннан файдаланган очракта);

опека яки попечительлек билгеләнүне раслаучы документ күчермәсе (кирәк булганда);

укырга кабул итүгә чираттан тыш, беренче чираттагы, өстенлекле хокукы булуны раслаучы документларның күчермәләре;

теркәлгән территориядә яшәү урыны яки тору урыны буенча баланы яки укырга керүчене теркәү турында документның күчермәсе яисә яшәү урыны буенча теркәлүне рәсмиләштерү өчен документлар кабул итү турында белешмә (беркетелгән территориядә яшәүче баланы яисә укырга керүчене кабул иткән очракта, яки башлангыч гомуми белем бирү программалары буенча укуга өстенлекле кабул итү хокукынан файдаланган очракта);

төп гомуми белем бирү программалары буенча укуга чираттан тыш, беренче чиратта кабул итү хокукын яки балигъ булмаган гражданнарны хәрби яки башка дәүләт хезмәтенә, шул исәптән Россия казаклары дәүләт хезмәтенә әзерләү максатыннан өстәмә гомуми үсеш программалары белән интеграцияләнгән төп гомуми һәм урта гомуми белем бирүнең белем бирү программалары буенча укуга өстенлекле кабул итү хокукын раслаучы документларның күчермәләре;

баланың ата-анасының (законлы вәкилләренең) эш урыныннан белешмә (укуга чираттан тыш яки беренче чиратта кабул итү хокукы булганда);

адаптив белем бирү программасы буенча укытырга психологик-медик-педагогик комиссия бәяләмәсенең күчермәсе һәм ата-аналарның (законлы вәкилләрнең) ризалыгы (сәламәтлек мөмкинлекләре чикләнгән балалар өчен).

Оешмада булганда һәм (яки) Оешманың вәкаләтле вазыйфаи затлары белән турыдан-туры хезмәттәшлек иткәндә – ата-ана (баланың законлы вәкиле) югарыда күрсәтелгән документларның төп нөсхәләрен, ә укырга керүче – укырга керүченең шәхесен раслаучы документның төп нөсхәсен бирә;

билгеләнгән үрнәктәге төп гомуми белем турында аттестат (урта гомуми белем алу өчен);

укучының шәхси делосы, агымдагы уку елында укучының өлгереше турында мәгълүмат булган башлангыч оешма мөһере һәм аның җитәкчесе яки вәкаләтле зат имзасы белән расланган документлар (агымдагы билгеләр һәм арадаш аттестация нәтиҗәләре белән сыйныф журналыннан өземтә) (башка оешмадан күчүче балалар өчен).

Чит ил гражданы булган яки гражданлыгы булмаган зат булып торган баланың ата-анасы (ата-аналары) (законлы вәкиле (законлы вәкилләре) яки чит ил гражданы булган яки гражданлыгы булмаган зат булып торган укырга керүче түбәндәгеләрне күрсәтә (күрсәтәләр):

гариза бирүченең (гариза бирүчеләрнең) туганлыгын (яки бала хокукларын яклау законлылыгын) раслаучы документларның күчермәләре;

чит ил гражданы булган яки гражданлыгы булмаган зат булып торган баланың

һәм аның законлы вәкиленең (законлы вәкилләренең) яки чит ил гражданы булган яки гражданлыгы булмаган зат булып торган укырга керүченең Россия Федерациясе территориясендә булуының законлылыгын раслаучы документларның күчермәләре (яшәүгә гамәлдәге рөхсәт яисә вакытлыча яшәүгә рөхсәт, яисә белем алу максатларында вакытлыча яшәүгә рөхсәт, яисә виза һәм (яки) миграция картасы, яисә чит ил гражданының яки гражданлыгы булмаган затның Россия Федерациясгородендә булу (яшәү) хокукын раслаучы, Федераль закон яки Россия Федерациясенең халыкара шартнамәсе нигезендә каралган башка документлар);

чит ил гражданы булган яки гражданлыгы булмаган зат булып торган баланың, яки чит ил гражданы булган яки гражданлыгы булмаган зат булып торган укырга керүчнең дәүләт дактилоскопик теркәлү узуын раслаучы документларның күчермәләре;

чит ил гражданы булган яки гражданлыгы булмаган зат булып торган баланың яки чит ил гражданы булган яки гражданлыгы булмаган зат булып торган укырга керүченең чит ил дәүләтенең (чит ил дәүләтләренең) белем бирү оешмаларында (2-11 сыйныфларда) рус телен өйрәнүен раслаучы документларның күчермәләре (булган очракта);

чит ил гражданы булган яки гражданлыгы булмаган зат булып торган баланың, яки чит ил гражданы булган яки гражданлыгы булмаган зат булып торган укырга керүченең шәхесен раслаучы документларның күчермәләре (чит ил гражданнары өчен: чит ил гражданының паспорты яисә федераль законда билгеләнгән яки Россия Федерациясенең халыкара шартнамәсе нигезендә чит ил гражданының шәхесен раслаучы документ буларак танылa торган башка документ); гражданлыгы булмаган затлар өчен: чит ил дәүләте тарафыннан бирелгән һәм Россия Федерациясенең халыкара шартнамәсе нигезендә гражданлыгы булмаган затның шәхесен раслаучы документ буларак танылa торган документ, Россия Федерациясендә вакытлыча яшәүгә рөхсәт, гражданлыгы булмаган затның вакытлыча шәхес таныклыгы, яшәүгә рөхсәт һәм федераль законда каралган яки Россия Федерациясенең халыкара шартнамәсе нигезендә гражданлыгы булмаган затның шәхесен раслаучы документлар буларак танылa торган башка документлар);

ата-анага (ата-аналарга) (законлы вәкилгә (законлы вәкилләргә) салым түләүченең идентификация номеры; индивидуаль шәхси счетның иминият номеры (алга таба — СНИЛС) (булган очракта) бирелүне раслаучы документларның күчермәләре, шулай ук чит ил гражданы булган яки гражданлыгы булмаган зат булып торган баланың, яки чит ил гражданы булган яки гражданлыгы булмаган зат булып торган укырга керүченең СНИЛСы (булган очракта);

чит ил гражданы булган яки гражданлыгы булмаган зат булып торган баланың, яки чит ил гражданы булган яки гражданлыгы булмаган зат булып торган укырга керүченең «Россия Федерациясендә гражданнарның сәламәтлеген саклау нигезләре турында» 2011 елның 21 ноябрендәге 323-ФЗ номерлы Федераль законның 43 статьясындагы 2 өлеше нигезендә Россия Федерациясе Хөкүмәте тарафыннан вәкаләт бирелгән федераль башкарма хакимият органы тарафыннан расланган исемлектә каралган әйләнә-тирәдәгеләр өчен куркыныч тудыра торган йогышлы авырулары булмау турында медицина бәяләмәсе;

ата-ана (законлы вәкил) тарафыннан хезмәт эшчәнлеген гамәлгә ашыруны раслаучы документларның күчермәләре (булган очракта).

Чит ил гражданнары һәм гражданлыгы булмаган затлар барлык документларны да рус телендә яки билгеләнгән тәртиптә расланган, рус теленә тәрҗемәсе белән тапшыралар.

Укуга кабул итү турында гаризаны ЕПГУ, РПГУ аша электрон формада

биргәндә, югарыда күрсәтелгән документларның күчермәләрен яки төп нөсхәләрен таләп итәргә рөхсәт ителми, чираттан тыш, беренче чиратта һәм өстенлекле укуга кабул итү хокукын раслаучы документларның күчермәләре яки төп нөсхәләреннән яки электрон рәвештә расларга мөмкин булмаган документлардан тыш.

Гариза бирүче үз теләге белән башка документларны тапшырырга хокуклы.

Кәгазьдәге гариза формасы гариза бирүче тарафыннан турыдан-туры Оешмадан алынырга мөмкин.

Күчереп алу һәм электрон формада тутыру өчен, гариза формасын белем бирү оешмасының рәсми сайтыннан алырга мөмкин.»;

3) 2.6.2 пунктчага түбәндәге эчтәлектәге абзац өстәргә:

«Кабул итү өчен чит ил гражданы булган яки гражданлыгы булмаган зат булып торган баланың ата-анасы (ата-аналары) (законлы вәкиле (законлы вәкилләре) яки чит ил гражданы булган яки гражданлыгы булмаган зат булып торган укырга керүче, өстәмә рәвештә, укырга кабул итү турындагы гаризада тест узу өчен ризалык бирә (бирәләр).»;

4) 2.8.2 пунктчаның икенче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Оешмада буш урыннар булмау, шулай ук мәгариф турындагы законның 78 статьясындагы 2.1 өлешендә билгеләнгән шартлар үтәлмәгәндә, мәгариф турындагы Законның 67 статьясындагы 5 һәм 6 өлешләрендә каралган очраклардан тыш.».

2. Башкарма комитетның эш кәгазьләрен алып бару идарәсенә әлеге карарны рәсми бастырып чыгаруны һәм аны «Интернет» челтәрендә Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында (http://pravo.tatarstan.ru), Яр Чаллы шәһәренең рәсми сайтында урнаштыруны тәэмин итәргә.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Башкарма комитет Җитәкчесе урынбасары В.Х. Харисовка йөкләргә.

Башкарма комитет
Җитәкчесе Ф.Ш. Салахов